МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

19 гыйнвар 2024 ел № М 17

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмәне раслау турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 48 статьясы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәрендә муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 18 апрелендәге 31/13 номерлы карары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмәне расларга.

2. Үз көчен югалткан дип танырга:

1) Шәһәр Хакименең «Муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннары турында» 2012 елның 21 сентябрендәге М 625 номерлы карары;

2) Шәһәр Хакименең «Шәһәр Хакименең «Муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннары турында» 2012 елның 21 сентябрендәге М 625 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 8 июлендәге М 306 номерлы карары;

3) Шәһәр Хакименең «Шәһәр Хакименең «Муниципаль хезмәткәрләрнең класс чиннары турында» 2012 елның 21 сентябрендәге М 625 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2021 елның 3 мартындагы М 99 номерлы карары.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары И.А. Сәгыйдуллинага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Яр Чаллы шәһәре Хакименең
2024 елның 19 гыйнварындагы
М 17 номерлы карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә
муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында
нигезләмә

1. Әлеге Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмә (алга таба – нигезләмә) белән Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль езмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе билгеләнә.

2. Класс чиннары муниципаль хезмәткәрләрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенең муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләү өчен квалификация таләпләренә туры килүен күрсәтә.

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең муниципаль хезмәткәрләренә (алга таба – муниципаль хезмәткәрләр) Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 9 статьясы нигезендә класс чиннары бирелә.

3. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары бирү һәм, муниципаль хезмәткәрләрне муниципаль хезмәтнең башка вазыйфаларына күчергәндә һәм муниципаль хезмәттән азат иткәндә, аларны саклап калу тәртибе Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясы нигезендә гамәлгә ашырыла.

4. Класс чиннары муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче муниципаль хезмәткәрләргә бирелә:

1) Хаким (Шәһәр Советы) аппаратында – муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары тәкъдиме буенча;

2) Башкарма комитетта – Башкарма комитет Җитәкчесе тәкъдиме буенча;

3) Башкарма комитет карамагындагы идарәләрдә һәм бүлекләрдә тапшырылган вәкаләтләр кысаларында – Башкарма комитет Җитәкчесе тәкъдиме буенча;

4) Контроль-хисап палатасында – Контроль-хисап палатасы Рәисе тәкъдиме буенча.

5. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары бирү өчен тәкъдимнәр (алга таба – тәкъдим) әзерләү кушымтада каралган форма буенча һәм әлеге нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документларны теркәп, җирле үзидарә органының структур бүлекчәсендә гамәлгә ашырыла.

6. Тәкъдимгә муниципаль хезмәткәрнең һөнәри әзерлек дәрәҗәсенең, муниципаль хезмәт вазыйфалары классификациясе нигезендә муниципаль хезмәт вазыйфаларына карата куела торган квалификация таләпләренә туры килүен раслаучы түбәндәге документлар (кәгазь һәм электрон йөрткечләрдә) теркәлә:

1) муниципаль хезмәткәрнең, аңа класс чины бирү нигезләрен күрсәтеп, җирле үзидарә органы җитәкчесе исеменә класс чины бирү турында язмача гаризасы;

2) муниципаль хезмәткәргә турыдан-туры аның җитәкчесе тарафыннан имзаланган һәм югарыда торучы җитәкче тарафыннан раслаган белем, күнекмәләр һәм осталык (һөнәри дәрәҗә) турында бәяләмә.

Бәяләмәдә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- муниципаль хезмәткәрнең фамилиясе, исеме, атасының исеме;

- муниципаль хезмәт вазыйфасы;
- аны бирү датасын күрсәтеп, муниципаль хезмәткәрнең класс чины (класс чины булганда);
- биләнә торган вазыйфа буенча эшчәнлек юнәлеше турында мәгълүматлар һәм муниципаль хезмәткәрнең җирле үзидарә органы функцияләрен гамәлгә ашыруга бәйле мәсьәләләрне хәл итүдә катнашу дәрәҗәсе;
- муниципаль хезмәткәрнең һөнәри дәрәҗәсенә дәлилләнгән бәя;
- муниципаль хезмәткәрнең яңадан һөнәри әзерлек узуы яки квалификациясен күтәрү турында мәгълүматлар.

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 10 статьясы нигезендә, муниципаль хезмәттә аерым казанышлары өчен бүләкләү чарасы буларак класс чины бирелгән очракта, югарыда күрсәтелгән документлардан тыш, тәкъдимгә муниципаль хезмәткәрнең турыдан-туры җитәкчесенең, әлеге нигезләмәнең 4 пунктында күрсәтелгән вазыйфаи зат тарафыннан килештерелгән нигезле үтенеч язуы теркәлә.

7. Әлеге нигезләмәнең 6 пунктында күрсәтелгән документлар, шәһәр Хакименең класс чиннары бирү турында карары проектын әзерләү өчен, Башкарма комитетның персонал белән эшләү һәм муниципаль хезмәт идарәсенә тапшырыла.

8. Муниципаль хезмәткәрләргә класс чиннары, барлык кирәкле документлар белән бергә класс чины бирү турында тәкъдим кертелгән көннән башлап бер айдан артмаган срокта, шәһәр Хакименең хокукый акты нигезендә бирелә.

Муниципаль берәмлек
Башлыгы урынбасары

И.А. Сәгыйдуллина

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында тәкъдимнәр кертү тәртибе хакында нигезләмәгә кушымта

Муниципаль хезмәткәргә класс чины бирү турында

ТӘКЪДИМ

1. Фамилиясе, исеме, атасының исеме ___________________________________________
4. Туу датасы: ______________________________________________________________
3. Вазыйфасы һәм эш урыны, билгеләнү датасы _______________________________
_____________________________________________________________________________
4. Сынау срогы (әгәр билгеләнгән булса) ____________________________________
5. Һөнәри белем турында мәгълүматлар _____________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
6. Гыйльми дәрәҗәсе, гыйльми исеме ________________________________________
7. Яңадан һөнәри әзерлек узу, квалификация күтәрү яки стажировка турында мәгълүматлар ____________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
8[i]. Квалификацион разряд, класс чины, бирелү датасы (әгәр булса) _____________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
9. Гомуми эш стажы ____________ Муниципаль (дәүләт) хезмәт стажы _____________
10. Муниципаль хезмәткәрнең белемен, күнекмәләрен һәм осталыгын (һөнәри дәрәҗәсен) бәяләү ___________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
11. Характеристика ___________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________
Класс чины бирү турында сорыйм ____________________________________________

Җитәкче «___»______ 20__ ел

_________________________

[i] Искәрмә: федераль дәүләт граждан хезмәтенең класс чины; дипломатик ранг; хәрби яки махсус исем; Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең яки Россия Федерациясенең башка субъектының класс чины; муниципаль хезмәтнең квалификация разряды; муниципаль хезмәтнең класс чины күрсәтелә.